Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

КАРАР

2017 елның 25 августы № 19/5

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә бер мәртәбә премия түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2013 елның 29 маендагы 32/6 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә бер мәртәбә бүләкләү тәртибенә һәм шартларына, түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«13. Компенсация түләүне гамәлгә ашырган җирле үзидарә органы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына Адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән социаль ярдәм күрсәтүнең күрсәтелгән чарасын бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә (ары - ЕГИССО) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп.».

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Э.С. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А.В. Шадриков